**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 27 декабрендәге 5443 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2019 елның 30 декабрендәге 4694 номерлы**
**«Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе карамагындагы аерым муниципаль оешмалар хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында»гы карарына**
**үзгәрешләр кертү хакында**

Аерым мәгариф учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләүне җайга сала торган муниципаль норматив хокукый актларны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 1 ноябрендәге 998 номерлы «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы карамагындагы аерым оешмалар хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында»гы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 6 июлендәге 553 номерлы, 2020 елның 30 декабрендәге 1237 номерлы, 2021 елның 26 июлендәге 645 номерлы, 2021 елның 30 октябрендәге 1030 номерлы, 2022 елның 20 июнендәге 587 номерлы, 2022 елның 26 августындагы 910 номерлы, 2022 елның 22 сентябрендәге 1027 номерлы, 2023 елның 16 октябрендәге 1312 номерлы, 2024 елның 10 июнендәге 416 номерлы, 2024 елның 26 сентябрендәге 832 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) туры китерү максатыннан **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2019 елның 30 декабрендәге 4694 номерлы «Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе карамагындагы аерым муниципаль оешмалар хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында»гы карарына (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 5 июлендәге 2125 номерлы, 2023 елның

12 гыйнварындагы 33 номерлы, 2024 елның 22 ноябрендәге 4789 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе карамагындагы аерым муниципаль оешмалар хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмәдә:

1.1.1. II «Казан шәһәренең аерым муниципаль мәгариф оешмалары мәгариф хезмәткәрләренең, мәдәният хезмәткәрләренең төп окладларын билгеләү» бүлеген түбәндәге редакциядә бирергә:

**«II. Казан шәһәренең аерым муниципаль мәгариф оешмалары мәгариф хезмәткәрләренең, мәдәният хезмәткәрләренең төп окладларын билгеләү**

2.1. Казан шәһәренең аерым муниципаль мәгариф оешмалары мәгариф хезмәткәрләренең төп окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| **Квалификация дәрәҗәсе** | **Вазифа атамасы** | **Айлык төп оклад күләме, сумнарда** |
|---|---|---|
| Беренче дәрәҗәдәге ярдәмче уку-укыту персоналының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Уку-укыту часте секретаре | 21473 |
| Икенче дәрәҗәдәге ярдәмче уку-укыту персоналының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Кече тәрбияче | 21583 |
| Педагогик хезмәткәрләр вазифаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Физик культура буенча инструктор | 22663 |
| | Музыка буенча җитәкче | |
| Икенче | Педагог-оештыручы | 22758 |

| | | |
|---|---|---|
| квалификация дәрәҗәсе | Социаль педагог | |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | Тәрбияче | 22858 |
| | Педагог-психолог | |
| | Өлкән инструктор-методист | |
| | Методист | |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | Өлкән методист | 22958 |
| | Тьютор (югары һәм өстәмә һөнәри белем бирү өлкәсендә эшләүче тьютордан тыш) | |
| | Укытучы-дефектолог | |
| | Укытучы-логопед (логопед) | |
| Структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазифаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Структур бүлекчә (кабинет, лаборатория, бүлек, бүлекчә, сектор, уку-укыту һәм консультация пункты, уку-укыту (уку-укыту һәм җитештерү) остаханәсе һәм балаларга гомуми белем бирү һәм өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыра торган башка структур бүлекчәләр, белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик яктан тәэмин итү буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган оешма [икенче кваликация дәрәҗәсенә кертелгән структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазифаларыннан тыш]) мөдире (башлыгы) | 23008 |

2.2. Казан шәһәренең аерым муниципаль мәгариф оешмалары мәдәният хезмәткәрләренең төп окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| **Вазифа атамасы** | **Айлык төп оклад күләме, сумнарда** |
|---|---|
| «Урта звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре | |

| Вазифа атамасы | Айлык төп оклад күләме, сумнарда |
|---|---|
| вазифалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Аккомпаниатор | 22820 |
| Түгәрәк, һәвәскәр берләшмә, кызыксынулар буенча клуб җитәкчесе | |
| «Әйдәүче звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазифалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Китапханәче | 23320 |
| Тавыш операторы | |
| «Мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләренең җитәкче составы вазифалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Сәнгать җитәкчесе | 24520» |
| Коллектив җитәкчесе | |

1.1.2. VII «Аерым муниципаль мәгариф оешмалары җитәкчеләренең, аларның урынбасарларының хезмәт хакын билгеләү тәртибе» бүлегенең 8 нче таблицасын түбәндәге редакциядә бирергә:

«8 нче таблица

**Аерым муниципаль мәгариф оешмалары җитәкчеләренең төп окладлары һәм алар тарафыннан башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләр күләме**

| Оешманың атамасы һәм төре | Төп оклад, бер айга сумнарда | Стимуллаштыру характерындагы түләү, сумнарда |
|---|---|---|
| Казан шәһәренең «Мәгариф хезмәткәрләре йорты» муниципаль бюджет учреждениесе | 30000,0 | 2000,0» |

1.2. Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе карамагындагы аерым муниципаль оешмалардагы эшчеләр, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре гомумтармак һөнәрләренең, җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазифаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары

турында нигезләмәнең II «Аерым муниципаль мәгариф оешмаларындагы эшчеләр, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре гомумтармак һөнәрләренең, җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазифаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең төп окладларын билгеләү» бүлеген түбәндәге редакциядә бирергә:

**«II. Аерым муниципаль мәгариф оешмаларындагы эшчеләр, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре гомумтармак һөнәрләренең, җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазифаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең төп окладларын билгеләү**

2.1. Аерым муниципаль мәгариф оешмаларындагы эшчеләр, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре гомумтармак һөнәрләренең һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең төп окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| **Квалификация дәрәҗәсе** | **Айлык төп оклад күләме, сумнарда** |
|---|---|
| «Беренче дәрәҗәдәге гомумтармак эшче һөнәрләре» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 21200 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 21398 |
| «Икенче дәрәҗәдәге гомумтармак эшче һөнәрләре» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 21539 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 21713 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | 21891 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | 22422 |

2.2. Аерым муниципаль мәгариф оешмаларындагы җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазифаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең төп окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| **Квалификация дәрәҗәсе** | **Айлык төп оклад күләме, сумнарда** |
|---|---|
| «Беренче дәрәҗәдәге гомумтармак хезмәткәрләр вазифалары» | |

| **Квалификация дәрәҗәсе** | **Айлык төп оклад күләме, сумнарда** |
|---|---|
| һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 21200 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 21398 |
| «Икенче дәрәҗәдәге гомумтармак хезмәткәрләр вазифалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 21539 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 21713 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | 21891 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | 22118 |
| Бишенче квалификация дәрәҗәсе | 22304 |
| «Өченче дәрәҗәдәге гомумтармак хезмәткәрләр вазифалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 22494 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 22687 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | 22884 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | 23085 |
| Бишенче квалификация дәрәҗәсе | 23311 |
| «Дүртенче дәрәҗәдәге гомумтармак хезмәткәрләр вазифалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 24223 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 24423 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | 24623 |

2.3. Хезмәткәрнең вазифасы һәм һөнәре эшчеләр, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре гомумтармак һөнәрләренең, җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазифаларының һөнәри квалификация төркемнәре буенча квалификация дәрәҗәләренә туры килүе Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының норматив хокукый актлары нигезендә билгеләнә.

2.4. Берьюлы ике эштә, шулай ук тулы булмаган эш вакыты шартларында эшләүче хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү эшләнгән вакытка пропорциональ рәвештә яки башкарылган эш күләменнән чыгып гамәлгә ашырыла. Төп вазифа, шулай ук берьюлы башкару тәртибендә биләгән вазифа буенча хезмәт хакы күләмен билгеләү һәр вазифа буенча аерым башкарыла».

2. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан гамәлгә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Г.Р.Сәгыйтовага йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**